**СОВЕТ**
**Исенбаевского сельского поселения**
**Агрызского муниципального района**
**Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы**
**Әгерҗе муниципаль районы**
**Исәнбай авыл җирлеге**
**СОВЕТЫ**

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

17.12.2021 Исәнбай авылы № 16-4

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Исәнбай авыл җирлеге Советының кайбер карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 48 статьясы, Татарстан Республикасының «Исәнбай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Исәнбай авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Исәнбай авыл җирлеге Советының кайбер карарларын үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Исәнбай авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Исәнбай авыл җирлегендә муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турында» 2013 елның 16 сентябрендәге 26-1 номерлы карары;

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының 2013 елның 16 сентябрендәге 26-1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Исәнбай авыл җирлегендә муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турында» Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Исәнбай авыл җирлеге Советының 2021 елның 10 июнендәге 9-2 номерлы карары;

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Исәнбай авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Исәнбай авыл җирлегендә муниципаль вазыйфалар биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Исәнбай авыл җирлегендә муниципаль вазыйфалар биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында Нигезләмәне раслау хакында» 2016 елның 01 апрелендәге 11-3 номерлы карары.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Исәнбай авыл җирлеге Советының «Санлы финанс активлары һәм цифрлы хокуклар турында белешмәләр бирү һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Исәнбай авыл җирлеге Советының керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакында» 2021 елның 16 августындагы 12-2 номерлы карары 2 пунктын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының портал составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: https://agryz.tatarstan.ru, шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Исәнбай авыл җирлеге территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында элеп халыкка чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы Ф.Ф.Сираев